| | |
|---|---|
| СОВЕТ НОВОИШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА ИШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

Яңа Ишле авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.04.2019 №43/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советының «Физик затларның милкенә салым турында " 2014 елның 19 ноябрендәге 47/2 номерлы карарының 2.3 пунктына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Ишле авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Ишле авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 47/2 номерлы карарының 2.3 пунктына (советның 2015 елның 27 апрелендәге 56/2 номерлы, 2015 елның 12 октябрендәге 2/1 номерлы, 2015 елның 18 декабрендәге 4/2 номерлы, 23.08.2018 № 30/1, 17.12.2018, 39/2 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), үзгәреш кертергә, :

"Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламаларын бирү турындагы гаризаны үз теләге белән тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документларны тапшырырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны Яңа Ишле авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Ишле авыл җирлеге башлыгы: Р.У.Мөхәммәтҗанов